ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.06.2022 г. Заинск № 301

**Зәй муниципаль районында Сөббух Рәфыйков исемендәге премияне бирү турында нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып,Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Расларга:

1.1. Сөббух Рәфыйков исемендәге премияне бирү турында нигезләмәне (1 нче кушымта).

1.2. Сөббух Рәфыйков исемендәге премияне бирү комиссиясе составын (2 нче кушымта).

2. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматрәсми порталында http://pravo.tatarstan.ruвеб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуныЗәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Р.Н. Камаловага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның «22» 06
301 номерлы карарына
1 нче кушымта.

## Сөббух Рәфыйков исемендәге премияне бирү турында нигезләмә

1. Сөббух Рәфыйков исемендәге премия милли мәдәниятне, әдәбиятны һәм сәнгатьне (сынлы, музыка, театр, декоратив-гамәли) үстерүгә зур өлеш керткән, югары һөнәри осталык дәрәҗәсе, авторның үзенчәлекле стиле, яңалыгы һәм оригинальлеге белән аерылып торган гражданнарның казанышларын тану максатларында бирелә.

2. Сөббух Рәфыйков исемендәге премиягә лаек булган затларга "Сөббух Рафыйков исемендәге премия лауреаты" исеме бирелә, акчалата бүләк һәм диплом тапшырыла.

3. Сөббух Рәфыйков исемендәге премия аерым шәхесләргә, һәм «яисә» иҗат коллективына бирелә (Лауреатларга кабат премия бирелми). Сөббух Рәфыйков исемендәге премиянең күләме, физик затлар керемендә салымны исәпкә алып, 50 мең сум тәшкил итә.

4. Кандидатларны тәкъдим итү 1 июньнән башлана һәм 1 июльгә кадәр дәвам итә. Конкурс турында белдерү массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыга.

5. Премиягә кандидатларны тәкъдим иткәндә комиссиягә түбәндәге документлар бирелә:

- кандидатны тәкъдим итү турында үтенечнамә;
- эш тасвирламасы;
- кандидатның авторлык эшенең иң мөһим элементлары турында күзалларга мөмкинлек бирә торган өстәмә күрсәтмә материаллар.

6. Тиешле документлар белән конкурс материаллары Сөббух Рәфыйков исемендәге премияне бирү комиссиясе тарафыннанпремиягә дәгъва итүче кандидатлардан документларны кабул итү тәгәлләнгәннән соң 3 эш көне эчендәкарала. Бирелгән материалларны карау нәтиҗәләре буенча комиссия Сөббух Рәфыйков исемендәге премия лауреатларын билгели, утырыш беркетмәсен әзерли.

7. Утырыш беркетмәсенә комиссия рәисе кул куя һәм Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә комиссия утырышыннан соң 3 эш көне эчендә җибәрелә.

8. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының Сөббух Рәфыйков исемендәге премияне бирү турында карары массакүләм мәгълүмат чараларында карар имзаланганнан соң 5 көн эчендә бастырып чыгарыла.

Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның «22» 06
301 номерлы карарына
2 нче кушымта.

**Сөббух Рәфыйков исемендәге премияне бирү комиссиясе составы**

**Комиссия рәисе:**
**Камалова Регина Николаевна** – Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары;

**Комиссия секретаре:**
**Батршина Сәрия Миннегали кызы** – «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы»муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе директоры, Зәй муниципаль районы Советы депутаты (килешү буенча);

**Комиссия әгъзалары:**

1. **Ананьева Ландыш Госман кызы** – Зәй муниципаль районы Советыныңаппарат җитәкчесе (килешү буенча);
2. **Биккинина Әминә Мулланур кызы**– Зәй муниципаль районы Советының иҗтимагый оешмалар, ММЧ белән эшләү һәм милләтара мөнәсәбәтләр бүлеге башлыгы (килешү буенча);
3. **Бахусова Анна Геннадьевна** – «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе» МКУ башлыгы вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча);
4. **Коронова Дина Борисовна** - «Зәй балалар музыка мәктәбе»өстәмә белем бирүМБУ директоры (килешү буенча);
5. **Костюченко Мария Филипповна** - Зәй муниципаль районыиҗтимагый советы рәисе (килешү буенча);
6. **Феофанова Гөлнара Миңнулла кызы**– «Татмедиа» АҖнең «Зәй-ТВ» телерадиокомпаниясефилиалы директоры - баш мөхәррир (килешү буенча).